РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан,
Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Советская, 24
тел. (8262) 48-3-31

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Сатыш авылы, Совет урамы, 24 йорт
тел. (8262) 48-3-31
e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.03.2019

КАРАР
№4

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт
ителми торган биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын урыннар турында

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тэртипкэ салу турында» Федераль законның 16 нчы матдәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары нигезендә, алкогольле продукцияне ваклап сату һәм алкогольле продукцияне ваклап сату урыннары чикләрен билгеләү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында төзелгән килешү нигезендә, иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафынннан тәртипкә салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» Федераль законның 16 нчы статьясындагы 2 нче пунктының 10 нчы пунктчасында күрсәтелгән биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын булган территориядә алкогольле продукцияне ваклап сату 10 метр радиуста рөхсәт ителми.

2. Якын булган территория чикләрен исәплəү өчен өстәмә территория исәплəү тәртибе отсчет нокталарыннан чыгып радиус буенча билгеләнә дип билгеләргә:

а) аерымланган территориял булган очракта - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең

җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында" карары белән расланган Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләренең (алга таба – кагыйдәләр буенча) 2 нче пунктында күрсәтелгән аерымланган территорияләргә йомыш белән килүчеләр өчен керү юлыннан;

б) кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән оешмалар һәм (яки) объектлар урнашкан бинага (төзелешкә, корылмага) аерымланган территория булмаганда.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар нигезендә күрсәтелгән Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән һәр оешма һәм (яки) объект өчен якын булган территорияләрнең чикләре схемасын эшләргә һәм расларга.

4. Гражданнар күпләп җыела торган урыннарда районкүләм чаралар үткәрү вакытында алкогольле продукцияне ваклап сату Сатыш авыл башкарма комитетының аерым карары белән регламентлана дип билгеләргә.

5. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Саба районындагы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Арча территориаль органына, Саба районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча Эчке эшләр бүлегенә федераль законнарның үтәлешен һәм әлеге карарның үтәлешен тикшереп торырга тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 1 нче декабрендә кабул ителгән 32 нчы номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/satish, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Шафигуллин